ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 3 өлешенең беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5; 2013, № 10; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Рәис итеп муниципаль район, шәһәр округы башлыгы (шәһәр эче муниципаль комиссиясендә – шәһәр округы җирле администрациясе территориаль органы җитәкчесе) билгеләп куела.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 11 ноябрь
№ 79-ТРЗ